КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 18 октябрь г.Казань № 900

2024 елда Татарстан Республикасы бюджетыннан Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына XVI БРИКС Саммитын уздыру чорында транспорт инфраструктурасы объектларының террорчылыктан сакланышы чараларын гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә финанс белән тәэмин итү чыганагы Татарстан Республикасы Министрлар Кабине-тының резерв фонды акчалары булган башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән 2024 елда Татарстан Республикасы бюджетыннан Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына XVI БРИКС Саммитын уздыру чорында транспорт инфраструктурасы объектларының террорчылыктан сакланышы чараларын гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә финанс белән тәэмин итү чыганагы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фонды акчалары булган башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 18 октябрь, 900 нче
карары белән расланды

2024 елда Татарстан Республикасы бюджетыннан Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына XVI БРИКС Саммитын уздыру чорында транспорт инфраструктурасы объектларының террорчылыктан сакланышы чараларын гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә финанс белән тәэмин итү чыганагы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фонды акчалары булган башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибе

1. Әлеге Тәртип 2024 елда Татарстан Республикасы бюджетыннан Казан шәһәре муниципаль берәмлеге (алга таба - муниципаль берәмлек) бюджетына XVI БРИКС Саммитын уздыру чорында транспорт инфраструктурасы объектларының террорчылыктан сакланышы чараларын гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә финанс белән тәэмин итү чыганагы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фонды акчалары булган башка бюджетара трансфертлар (алга таба- башка бюджетара трансфертлар) бирү механизмын билгели.

2. Башка бюджетара трансфертлар Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына (алга таба - Министрлык) җиткерелгән бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә 2024 елга әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга бирелә.

3. Башка бюджетара трансфертлар бирү шартлары:

финанс белән тәэмин итүгә башка бюджетара трансфертлар бирелә торган чаралар исемлеген раслый торган муниципаль хокукый акт булу;

Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль берәмлек бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү турында килешү төзү (алга таба - килешү).

4. Башка бюджетара трансфертлар бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

муниципаль берәмлек тарафыннан бу Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән башка бюджетара трансфертлар бирү шартларын үтәмәү;

бу Тәртипнең 5 пунктында каралган документларның тапшырылмау (тулы күләмдә тапшырылмавы).

5. Башка бюджетара трансфертлар алу өчен муниципаль бермәлек җирле үзидарәсенең вәкаләтле органы Министрлыкка Министрлык тарафыннан билгеләнгән срокларда түбәндәге документларны тапшыра:

Министрлык тарафыннан расланган форма буенча башка бюджетара трансфертлар бирү турында заявка;

заявкага кул куйган затның вәкаләтләрен раслый торган документ;

финанс белән тәэмин итүгә башка бюджетара трансфертлар бирелә торган чаралар исемлеген раслый торган муниципаль хокукый актның таныкланган күчермәсе.

6. Муниципаль бермәлек җирле үзидарәсенең вәкаләтле органыннан кергән документлар Министрлык тарафыннан алар кергән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә карап тикшерелә. Документларны карап тикшерү йомгаклары буенча Министрлык башка бюджетара трансфертлар бирү турында йә башка бюджетара трансфертлар бирүдән баш тарту турында карар кабул итә, эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә бу турыда, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, муниципаль бермәлек җирле үзидарәсенең вәкаләтле органына хәбәр итә.

Муниципаль бермәлек җирле үзидарәсенең вәкаләтле органы бу Тәртиптә билгеләнгән таләпләрне үтәү шарты белән башка бюджетара трансфертлар бирүдән баш тарту турындагы хәбәрнамәне алган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә яңадан заявка бирергә хокуклы.

Яңадан бирелгән заявкаларын карап тикшерү тәртибе беренче тапкыр бирелгән заявкаларны карап тикшерү тәртибе белән охшаш.

7. Башка бюджетара трансфертлар Министрлык һәм муниципаль берәмлек җирле үзидарәсенең вәкаләтле органы арасында Татарстан Республикасы Финанслар министрлыгының «Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетка башка бюджетара трансферт бирү турындагы килешүнең бертип формасын раслау хакында» 2021 елның 18 декабрендәге 17-112 номерлы боерыгы белән расланган бертип форма буенча төзелә торган килешү нигезендә бирелә (алга таба - килешүнең бертип формасы).

8. Башка бюджетара трансферт күләме Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән билгеләнә.

9. Транспорт инфраструктурасы объектларының саны башка бюджетара трансферт бирү нәтиҗәсе булып тора, аларда XVI БРИКС Саммиты уздыру чорында террорчылыкка каршы якланганлык тәэмин ителгән.

10. Муниципаль берәмлек тарафыннан башка бюджетара трансфертлардан файдалануның нәтиҗәлелеген бәяләү Министрлык тарафыннан килешүдә билгеләнгән башка бюджетара трансфертлар нәтиҗәлелеген фактта ирешелгән күрсәткечләре белән чагыштыру аша гамәлгә ашырыла.

11. Муниципаль бермәлек җирле үзидарәсенең вәкаләтле органы Министрлыкка финанс белән тәэмин итү максатларында башка бюджетара трансферт бирелә торган чыгымнар турында һәм аңа ирешү максатларында кабул ителгән башка бюджетара трансферт һәм йөкләмәләр бирү нәтиҗәсенең мәгънәсенә ирешү турында хисапны Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән килешүнең бертип рәвешенә кушымта итеп бирелә торган рәвешләр буенча килешү төзүдә каралган срокларда тапшыра.»;

12. Муниципаль берәмлекнең җирле үзидарәсенең вәкаләтле органы тапшырыла торган хисап белешмәләренең дөрес булмавы һәм башка бюджетара трансфертлардан максатчан файдаланмаган өчен законнар нигезендә җаваплы.

13. Башка бюджетара трансфертлар килешү төзелгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә муниципаль берәмлекнең финанс органына ачылган муниципаль район бюджетының бердәм счетына күчерелә.

14. Муниципаль берәмлек тарафыннан башка бюджетара трансферлар бирү шартлары бозылган очракта, аңа карата Россия Федерациясе бюджет законнарында каралган мәҗбүр итүнең бюджет чаралары кулланыла.

15. Муниципаль берәмлек тарафыннан килешүдә билгеләнгән башка бюджетара трансфертлар бирү нәтиҗәсенә ирешелмәгән очракта, башка бюджетара трансфертлар 2025 елның 1 мартына кадәр муниципаль берәмлек бюджетыннан Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш.

16. Башка бюджетара трансферлардан максатчан файдаланылмау Татарстан Республикасы бюджетыннан алынган акча суммасын законнар белән билгеләнгән тәртиптә бәхәссез түләтүгә китерә.

17. 2025 елның 1 гыйнварына карата файдаланылмаган башка бюджетара трансфертлар акчасы 2025 елның беренче 15 эш көне эчендә Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

18. Башка бюджетара трансфертларның файдаланылмый калган өлеше Татарстан Республикасы бюджеты керемено күчерелмәгән очракта, әлеге акча, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән гомуми таләпләрне үтәп, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә Татарстан Республикасы бюджеты керемено түләтелергә тиеш.

19. Министрлык һәм дәүләт финанс тикшерүе органнары бу Тәртип һәм килешү белән билгеләнгән башка бюджетара трансфертлар бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыра.

20. Башка бюджетара трансфертларны максатчан файдалануны контрольдә тоту Министрлык тарафыннан Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.